ТУГАН ҖИРКӘЕМ

Энҗе МӨЭМИНОВА

Һәйкәлләр сөйли

Авылыбызның урта бер җирендә,
Иң матур, иң калку урында
Һәйкәл булып баскан солдат тора,
Автоматын тотып кулына.
Иңенә салган плащ-палаткасы
Кире кага салкын җилләрне.

Кисәтүле караш бөркеп тора
Кырыс, җитди, уйчан күзләре.
Әйтә сыман алар:
— Тукта, иптәш, тукта!
Минем яннан
Тыныч кына үтеп китмә син!
Мин бит гади таш сын гына түгел,
Мин көрәшче! Ватандашың синең, иптәшең!
Мин ялгызым түгел, без — күпләр!
Миллионнар — минем кебекләр...
Менә шуның өчен минем яннан
Тыныч кына үтеп китмә син!
Бер минутка гына туктал да син,
Тирә якка күз сал! —

Нинди матур синең тирә-ягың,
Йокың нинди тыныч!
Гүзәллекне, шушы тынычлыкны
Саклау — синең бурыч.
Күрәсеңме, мәйдан уртасында
«Мәңгелек ут» яна! —
Безнең йөрәкләрнең ялкыныннан
Ут кабынган аңа!
Менә шуның өчен безнең яннан
Тыныч кына үтеп китмә син.
Бер минутка туктал,
Туктал да син,
Безне искә ал!
Бер минутка тын кал.

БӨЕК ҖИҢҮГӘ-65 ЕЛ

СЫНАУЛАРНЫҢ ҮТТЕК ТӨРЛЕСЕН

Газизнең бала чагы илдә-авылда кешеләрне сортларга аерып, аларга ярлык таккан чорга эләгә. Әтисе Сабирҗанның җил тегермәне булган. Шуңа күрә ул кулак тамгасы ала.

1926 елда туды дип фаразланган (таныклыгы сакланмаган) Газизне, 1943 елның 10 ноябрендә армиягә алганда аның Насыйр һәм Гани исемле абыйлары фронтта була. Гани исә яу кырында — II Белоруссия фронты составында сугышканда һәлак булып кала.

Газизне башта Суслонгер лагеры көткән булып чыкты. Әле дә ярый, нарат ылысының төнәтмәсе коткара. Үпкәсе кабаруын төнәтмә эчеп бетерә Сабиров.

— Занятиегә дип алып китәләр дә, мылтыкларны пирамида итеп куйдырганнан соң, ботамаган нарат агачын күтәртеп станциягә җибәрәләр. Аяк киеме тишелеп бетте. Ашау бик начар. Гөмбә җыеп пешергәнне күрсәләр, котелокларны тибеп очыралар иде. Молдаваннарга посылкалар килде. Шундагы ризыкларны ашагач, кинәт һәм күп ашаудан бик күпләр үлде. Бу лагерьдан комиссия үткәреп озатканда минем авырлык 44 килограмм иде, — дип искә ала бүген Газиз ага.

Малайлар авырлыгындагы Газиз солдат Суслонгердан II Белоруссия фронтына озатыла. Минскига таба юл тота алар. Ник бер исән авыл күренсен дә, бер тере кеше очрасын. Сугыш афәтеннән кешеләр урманга качып беткәннәр икән.

Окоплар, траншеялар казып оборонага урнаштырылган солдатларны күп тә үтми һөҗүмгә күтәрәләр. Минск шәһәрен азат итү бурычы куела аларга.

— Кояш баеганда бу шәһәрне азат иттек. Иттек дип әйтүе генә җиңел. Ярый әле, немецлар безне бомбага тотарга әзерләнәләр дип разведка хәбәр иткән иде, — дип искә ала ул бүген.

Әнә шулай Газиз Сабиров, фронтка бәйле елларын искә төшерә башлады.

Минскидан соң пехота солдатының юлы Литва җирендә дәвам итә. Чираттагы бер һөҗүм вакытында снаряд ярчыгыннан яралана. Шул яралануы нәтиҗәсендә уң кулындагы өч бармагы өзелә. Операциядән соң Смоленскига, аннан Мәскәү өлкәсенә җибәрелгән Газизнең гомуми халәте бераз яхшыра төшә. «Госпитальдә, — ди ул, — яхшы ашаттылар. Лагерь начальнигы миңа шул хәлеңдә тагын ике ай йөрсән үләчәк идең. Каның беткән бит, диде».

Әнә шундый хәлгә килгән Газизне фронтка кире кайтармыйлар. Башта Мәскәүдәге 94 нче заводта, аннан соң Ленинградтагы Жданов исемендәге заводта эшләтәләр. Дөрес, соңгысында эшләү дигән төшенчә әсирлеккә эләккән немец солдатларын саклаудан, тимер юл төзеткәндә аларга күз-колак булудан гыйбәрәт була. «Немецлар үзләре бомбага тоткан тимер юлны төзеделәр. Әйбәт ашаталар иде аларны, итле ризык бирәләр иде. Безгә шул ипи дә, көбестә шулпасы». Бу җөмлә дә Газиз ага авызыннан яңгырады.

Яраланган, физик яктан таушалган солдатны өенә кайтарып җибәрергә ашыкмыйлар. Бу юлы инде юл икенче якка — Мурманск тарафларына таба булып чыга. Һава шартлары тиз алышына торган бу якларда да язмыш елмаймый Газизгә. Цинга авыруыннан газап чигә. Тешләре коелып бетүдән тюлень мае гына коткара аны. «Бер тәүлеккә бирелгән 500 грамм ипине икегә бүләм дә, бер кисәген йә тюлень маена, йә балыкныкына алыштыра идем. Сакта тору өчен киез итек киеп барасың. Яңгыр яугач ул чыланып бетә. Өстәге кием дә тәнгә ябыша. Бик нык авырдым мин монда», — дип искә алды Газиз ага.

Шундый хәлдәге солдатны Мәскәүгә — хәрби объектларны саклага кайтаралар. Әнә шунда Җиңү дигән озак көтелгән, изге вә кадерле сүз колагына ирешә аның.

Туган якка кайткач Наласа авылы кызы Рокыяга өйләнә ул. Рокыя күп авырлыклар күргән, сугыш вакытында Курса Почмакта паравозга ягу өчен утын әзерләүдә катнашкан, Мәндеш авылында яшәп вагоннарга агач төяшкән кыз буларак, Газизгә ныклы таяныч, балаларга миһырбанлы ана була. 3 кыз, 1 ул дөньяга килгән бу гаиләдә бер-берсен ихтирам итешеп яшәү бүгенге көндә дә дәвам итә әле. Зөлфирәләре төп йөкне тартып, әти-әнисен тәрбияләүне үз өстенә алса, Илсөя белән Зөһрәләре дә туган йортка сукмакларын өзмиләр. Биектауда үз йорты белән яшәүче Зөфәрләренең дә кулыннан килмәгән эше юк.

Үткән гомер йомгагын сүткәндә Газиз ага Сабиров шәхси архивындагы орден-медальләрен, бүгенгәчә сакланган төрле белешмәләрен күздән кичерергә ярата. Ул кәгазьләрнең берсенә — республика прокуроры кул куйганына аеруча озак карап тора ул. Әйе, әтисе Сабирҗан Мөхәмәтҗановның реабилитацияләнүе турында язылган юллар якын, бик якын аңа.

Харис ЗАКИРОВ.
Казан — Арча — Наласа.

ЯҢАЛЫКЛАР

✓Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Алабуга, Мамадыш һәм Теләче районнарында язгы кыр эшләре барышы белән танышты. Республика башлыгы Иске Җөри авылында «Татарстан ВАМИН» җәмгыятенең 1500 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән терлекчелек комплексында булды. Аны ТР Премьер-министры урынбасары — авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов озатып йөрде. Семинар-киңәшмәдә җәмгыять эшенә анализ ясалды.

✓Татарстанда авыл хуҗалыгы мәйданының 48 процентын бөртекле культуралар били. 857 мең гектар мәйданда рапс, шикәр чөгендере һәм башка авыл хуҗалыгы культуралары чәчелгән. Нурлат районы язгы чәчү эшләрен кызу темпта алып бара, бүген анда 80 процент мәйданда эшләр төгәлләнгән. Зәй районында — 63, ә Чүпрәле һәм Баулыда — 62 процент мәйданда бөртекле культуралар чәчелгән. Ә менә Әгерҗе, Алабуга, Актаныш, Әтнә, Югары Ослан, Азнакай һәм башкаларга чәчү темпларын тизләтергә кирәк.

✓Республика клиник хастаханәсе, Бөгелмә, Алабуга, Яңа Чишмә, Чистай һәм Казанның 5-нче хастаханәсе җитәкчеләре Татарстан Хөкүмәте гранты нигезендә Израиль дәүләтенең алдынгы клиникаларында стажировка уздылар. Табиблар Тель-Авив шәһәрендәге Ассута шәхси госпиталенең диагностика һәм диспетчер үзәкләрендә, И.Рабин исемендәге дәүләт госпиталендә, Хайфа шәһәрендәге Кармэль клиникасында булып, гомум-практика табибларының эше белән таныштылар.

✓Казандагы сугыш ветераннары өчен госпитальдә call-үзәк ачылды. 23-91-911 номеры буенча шалтыратып, дәвалау процессы, консультатив сырхауханә эшенә караган сорауларны биреп була. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайты хәбәр иткәнчә, алга таба Пенсия фонды, иминият компанияләре белән бәйләнешкә керү планлаштырыла. Call-үзәкнең максаты — һәр кешегә сыйфатлы ярдәм күрсәтү, пациентның хәлен җиңеләйтү. Госпиталь администраторлары иртәнге 8дән 20 сәгатькә кадәр пациентларны чиратка яздыра, киңәшләр бирә һәм белгечләргә җибәрә.

✓Казанда икенче тапкыр Коръән уку бәйгесе уздырылды. Татарстан башкаласында төгре тапкыр кызлар арасында ачык Коръән бәйгесе моннан ике ел элек узган иде. Ул чакта анда бөтен Россиядән 70 мөслимә катнашты. Быел исә конкурска 95 заявка килгән. Икенче тапкырга аларның 26сы үткән. Оештыручылар билгеләп үткәнчә, Казан бәйгесе Россиядә халыкара стандартлар нигезендә уза торган бердәнбер бәйге булып тора.

✓«Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Созвездие-Йолдызлык-2010» республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең гала-концерты узды. Чара Бөек Ватан сугышында җиңүебезгә 65 ел тулуга багышланган иде. Гала-концертта Казан һәм республикабызның башка шәһәр-районнарыннан эстрада-вокал һәм хореография коллективы, аерым башкаручылар — барлыгы 400гә якын яшь талантлар чыгыш ясады. Фестиваль лауреатларын котларга Мәскәүдән дә кунаклар килгән иде.

НИ ХӘЛЕҢ БАР, АВЫЛ?

ТИРСӘ ЭШМӘКӘРЛӘРЕ

«Авылдашлар» эшли белә

Журналист кеше өчен кайчандыр матбугатта бастырып чыгарган язмасының герое белән очрашу гайре табигый хәл түгел. Моннан 12 ел элек миңа Әгерҗе районының Тирсә урта мәктәбе, аның директоры Раил Газиз улы Харисовның яңа бина салдырып, анда кабинет системасы булдыруы, беренчеләрдән булып арендага җир алуы, шуннан кергән акчага кечкенә бер «колхоз» оештыруы, тәҗрибәләренең республикага тәкъдим ителүе турында язарга туры килгән иде. Һәм менә яңадан очрашу — бу юлы шәхси оешма җитәкчесе белән. Ул — «ИП Харисов Р.Г. Терсинский молочный комбинат «Авылдашлар» дип атала.

Илдә үзгәрешләр барган заманда республикага танылган мөгаллим югалып калмаган. Тирсә, Мордывый, Көчек авыллары шәхси хуҗалыкларыннан сөт сатып алып, аннан берничә төр продукт җитештерергә керешкән. Бу изге гамәлендә аңа ике улы — Равил һәм Наил булыша.

Равил әнә КамАЗда мастер булып эшләгән җиреннән әтисе оештырган «Авылдашлар»ны «тартып» барышырга кайткан. Моңа кадәр Наил дә туган нигезендә ял көннәрендә генә күренә торган булган. Бу җәһәттән караганда, Раил Газизович улларына гына түгел, тагын 19 кешегә эш урыны булдырган.

Аталы-уллы Харисовлар.

— Сөт күп керәме. Аннан нәрсәләр җитештерәсез? — дим Раил әфәндегә.

— Сыерлар ташланып торган мәлдә 1,0-1,2 тонна сөт җыябыз. Шоферыбыз Илфат Зәйнуллин белән Альфред Галиуллин һәр көнне авылларны урап кайталар. Эшкәртелгән сөттән 19 килограмм май, 170 килограмм каймак алабыз. Шушы төр продуктлардан тыш, эремчек, катык, корт җитештерәбез. Сыерлар бозаулый башлагач ризыкларның күләме дә арта төшә.

— Аларны кайда сатасыз соң?

— Нигездә, Чаллыда. Анда 5 сатучыбыз бар. Кешегә нәрсә һәм күпме кирәк — шуны үлчәп бирәләр. 250-350 грамм каймак сыешлы пластмасс савытлардан да файдаланабыз. Ул савытларны Чаллы сөт заводы кибетеннән алабыз.

Әнә шулай дип җавап бирде комбинат җитәкчесе. Яше җитеп лаеклы ялга чыкса да, Раил Газиз улы дәртләнеп, фикерләренә ачыклык кертеп сөйли. Аның киләчәккә планы төзеп куелган инде. Комбинат өчен офис, гараж салу, «ГАЗель» алу, көнлек сөт эшкәртү күләмен 5 тоннага җиткерү — якын арадагы планы әнә шуннан гыйбәрәт аның.

— Билгеләнгән планнарыңны тормышка ашыру өчен финанс мәсьәләсен хәл итәргә кирәктер бит. Сөт саткан кешеләр белән дә исәп-хисапны ясарга кирәк. Бу җәһәттән эшләр ничегрәк тора?

Чираттагы соравыма җавап итеп, Раил Газизович хөкүмәт биргән кредитның нык ярдәм итүен сөйләп алды. Шәхси ярдәмчел хуҗалык өчен бирелгән 16% лы кредитның берникадәр өлешен хөкүмәт каплый икән. Харисовлар гаиләсе, үз-үзенә эш табу (самозанятость) программасында катнашып, 300 мең сумлык Татарстан хөкүмәте грантына лаек булган. Алган кредит һәм кергән акчаларга Тирсәдә урнашкан «Сельхозхимия» берләшмәсенең икмәкханәсе булган бинаны алырга исәпләвен дә яшермәде ул. Үзләренең клиентлары белән исәп-хисап исә төпле бер тәртип белән башкарыла икән.

— Без һәр дүшәмбедә, сөтнең бер килограммына 10 сум исәбеннән, документка кул куйдырып акча бирәбез, — ди, әтисенең төп ярдәмчесенә әверелгән Равил әфәнде.

Ите дә, мае да үзләренеке

Бу авылда булганда, шәхси хуҗалыклар турында Федераль закон кабул ителгәнче үк шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башлаган Хәбировларга да сугылып чыгарга туры килде. Бүгенге көндә Әлфинә һәм Фирдәвес Хәбировлар хуҗалыгында 15 ләп мөгезле эре терлек, зурысын-бәләкәен кертеп 10нан артык дуңгыз, байтак кына тавык-чебеш асрала. Әлбәттә инде, алар тиешле авырлыкка җиткерелгәч, юлны базар ягына тоталар. Сатып алучылары Ижау һәм Әгерҗедә яшәүчеләр икән. Алар Әлфинә ханым пешергән чәк-чәкне дә, ул ясаган дуңгыз салосын да, тавыклар салган йомыркаларны да яратып алалар. Шулай ук кишер һәм сарымсак кебек яшелчәләрдән дә баш тартмыйлар икән.

— Бу кадәр мал-туарны тоту өчен көч күп сорала бит. Сез ничек барысына да өлгерәсез? — дим, Әлфинә ханымга.

— Ирем Фирдәвес бик тырыш кеше. Нинди генә оешмада эшләсә дә гел алдынгы булды. Хәзер дә «Ак Барс — Әгерҗе»нең Тирсә филиалында «КамАЗ» йөртә. Аннан башка бу хуҗалыкны алып бара алмас идем. Аннан соң кызларыбыз Лилия белән Лизия дә бик тырышлар. Чаллыда яшәсәләр дә, ял саен кайталар, бөтен эшләрне башкарып китәләр, — ди ул, үзенең җавабында.

Әлфинә Хәбирова.

Халыкта эшләгәннең ашы бар диләр. Хәбировларга «аш» болын кадәр кирпич өй салу, кызларының икесенә дә югары белем алу өчен мөмкинлек тудыру булып кайткан.

Әлбәттә, үз эченә 5 авылны, 793 хуҗалыкны берләштергән Тирсә авыл җирлегендәге башка эшмәкәрләр турында да авыз тутырып сөйләргә мөмкин. Мәсәлән, Назим Османов, Хәйдәржан Хәкимов, Фәһимә Хәкимова, Тәлгать Әхмәтҗанов, Рафинат Низамбиев, Альберт Әхмәтшиннар турында. Шунысы куанычлы: шәхси ярдәмчел хуҗалыкларның эшчәнлеген яклауны күздә тоткан республикабызның 2013 елга кадәр кабул ителгән махсус программасының нәтиҗәсе Әгерҗе районының күп төбәгендә күренә. Һәм Тирсә авыл җирлеге мисалында да.

Харис ЗАКИРОВ.
Казан — Әгерҗе — Тирсә.

ФИКЕР

Чын милекче бармы?



Кайбер түрәләр, Россиядә совет заманындагы һәм үткән гасырның туксанынчы елларындагы кебек ашамлыкларга, бигрәк тә халыкның аз тәэмин ителгән катлавы өчен талон системасы кертергә кирәк, дип акыл саталар. Шулай итеп, алар илнең киләчәктә үз халкын азык-төлек белән тәэмин итә алу мөмкинлеген шик астына куя. Бер уйлаганда, моның өчен нигез дә бар кебек. Россия — аграр держава, дигән исемен югалтты. Кибет киштәләре, супер-гипер маркетлар чит ил ризыклары белән тулган. Ипи, сөт, йомырка, яшелчә үзебезнеке җитә, дип мактансак та, читтән кергәннәре белән, шөкер, әлегә җитеп бара. Халыкара практика күрсәткәнчә, чит илләрдән кергән ашамлыклар 25 проценттан артмаса гына халыкка азык-төлек куркынычы янамый. Хәзер ул бездә 35 процент тәшкил итә.

Хәлнең кискенләшә баруына юл куймау өчен безгә авыл хуҗалыгын алып баруның дәүләт ярдәменнән башка мөмкин түгеллеген инде аңларга вакыт. Шунсыз авыл хуҗалыгы предприятиеләре, фермерлар да, шәхси крестьян хуҗалыклары да табышлы эшли алмаячак. Әлегә авылның төп терәге, төп таянычы булып шәхси хуҗалыклар кала. Бүген Россия Федерациясендә бәрәңге һәм яшелчәнең дүрттән бер өлешен, итнең 40 процентын, сөтнең 50 процентын алар җитештерелә.

Әгәр дә Көнбатыш илләре берәр сәбәп табып, безгә ашамлыклар бирүне туктатсалар, һәм шәхси хуҗалыкларга терлек асрауда, хуҗалыкны алып баруда даими ярдәм күрсәтмәсәләр, төп башына утырып калуыбыз да ихтимал.

Әмма алга таба хәлнең яхшырачагына мин үзем бик өметләнмим. Менә ни өчен? Авыллардан кешеләр китә. Халык мал-туарны элеккедән дә аз асрый. Чөнки терлек азыгы юнәлтү кыенлашты. Инвесторлар килеп эшли башлагач бигрәк тә. Алар үз мәнфәгатләрен кайгырталар. Социаль мәсәләләр турында уйламыйлар. Ә шуларны хәл итми торып, авылда яшәү бик кыенга туры киләчәк. Хезмәт хакы түбән, крестьян анысын да вакытында ала алмый. Илне фермерлар туйдырачак дип шау-гөр килеп йөргән демократларның планы барып чыкмады. Алар, авыл — кара тишек, аңа күпме акча бирсәң дә рәт чыкмаячак, әнә чит илләргә нефть, газ, металл, агач сатарбыз да, ашамлыклар сатып алырбыз, дип илнең авыл хуҗалыгын язмыш кочагына ташладылар. Шуннан җирне уңга-сулга тарату башланды. Хөкүмәт башында утыручылар да җитәрлек дотоция бирмичә, авыл хуҗалыгын финансламыйча Янәсе, АКШта, Канада да, Көнбатыш Европа илләрендә җирдә хосусый милекчеләр эшли. Аларның халкы балда-майда йөзә. Тик Россия реформаторлары чит илләрдә авыл хуҗалыгын алып баруның серенә төшенеп тормадылар. Чөнки аларга тизрәк күмәк хуҗалыкларын таратырга туры килде. Ә бит чит илләрдә хәл башкача. Анда җиргә хосусый милек итеп кенә карамыйлар, алар өчен ул — хуҗалык итү формасы, һәм аннан продукция алуның төп чыганагы.

Бүген Россия Хөкүмәте авыл хуҗалыгына күрсәткән ярдәм һич тә җитәрлек түгел. Шуңа күрә дә илнең миллионларча гектар җирендә чүп үлән котырып үсә. Совет власте заманында төп ашамлыкларны җитештерү буенча без Җир шарында 5-6 урыннарны алып торсак, бүген Россия 78-80 урыннарга төште.

Шннан соң сорау туу бик табигый: без җирне хосусый милеккә бирәп, оттыкмы, оттырдыкмы? Ашлыкны күп җитештерү генә әле яңа төр авыл хуҗалыгы предприятиеләренең өстенлеге турында сөйләми. Җирне хосусый милеккә бирдек, ә чын милекче барлыкка килмәде. Авыл кешеләре пай җирләрен үзара килешү буенча инвесторларга, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә бирделәр. Ә күп кенә кешеләр аны сатып та җибәргәннәр. Кайберләре пай җиренең кайда икәнен дә белми. Җирен арендага бирәп торучылар да, тиешлесен ала алмый.

Бу яктан белорусслар үтә зирәклек күрсәттеләр, һәм шуның белән оттылар да. Монда крестьяннар Хөкүмәттән дотацияләр алып, элек ирешелгәнен саклап калдылар. Белоруссия үзеннән арткан продукциясен чит илләргә дә сата. Безнең Казан кибетләрендә һәм базарларда бу илдән китерелгән сырлар һәм башка ризыклар сатыла. Хикмәт шунда, белорусслар авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштырмадылар, колхоз-совхозларны саклап калдылар.

Бездә шундый караш яши: хосусый милекчеләр генә җирдә эшли белә. Алар гына авыл хуҗалыгы продукциясен күп җитештерергә сәләтле. Шулаймы соң? Җиргә хосусый милек булган Азия, Африка, Латин Америкасының кайбер илләре азык-төлек кытлыгы кичерәләр икән, ә Голландия, Израил кебек авыл хуҗалыгы нык алга киткән илләрдә, җир дәүләт кулында икән, моны ничек аңларга соң?

Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршындагы иң абруйлы һәм 200 гә якын члены булган ФАО дигән аграр оешма авыл хуҗалыгындагы яңарышларга китерүче факторларны өйрәнеп нәтиҗә ясаган. Шуның буенча әзерләнгән докладта, җиргә хосусый милек турында бер сүз дә юк. Бу җирне хосусый милеккә бирүгә сак каррга кирәк диюеме, әллә хосусый милеккә нигезләнгән авыл хуҗалыгында эшләрнең бик үк мактанырлык булмавы турында сөйлиме? Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе академигы, танылган галим Владимир Милосердов болай ди: «Көнбатыш илләреннең галимнәре фикеренчә, җиргә хосусый милекченең хокукларын дәүләт тарафыннан чикләү принцибы нигезле һәм ул җәмгыяттәге социаль киренкелекне бетерә. Шуңа күрә җир хуҗалары турында сүз алып бару урынлы булыр... Безнең җитәкчеләр, Көнбатышның милек һәм хуҗалык итү формаларын алып, соңгы вакытта җир турындагы закондагы тендецияләрне күрмәмешкә салыштылар. Ә бу тенденцияләр бөтенләй үк булмаса да, тарихи ялгышлыкны — җиргә хосусый милек урнаштыру буенча җибәрелгән ялгышны төзәтүдән гыйбәрәт».

Мин үзем һич кенә дә яңадан колхоз-совхоз формасына кайтырга өндәмим. Ләкин авылны саклап калу өчен тагын да нәтиҗәлерәк чаралар, иң мөһиме — җитәрлек финанслау чаралары күрелмәсә, крестьян эшләгәненең әҗерен күрмәсә, җирдә хуҗалык итүнең бернинди формасы да уңыш китермәячәк. Авыл гел инвестор күзенә генә карап яши алмый. Ул да берзаман китәр. Аның үз мәшәкате дә җитәрлек. Ә авыл нинди хәлдә калыр? Монысын күз алдына китерү кыен түгел.

Мөнир АБДУЛЛИН.

cyan magenta yelow black

ШӘХСИ ХУҖАЛЫКЛАРДА

ТЫРЫШКАН ТАШКА ДА КАДАК КАГАР

Менә ул такта яру цехы егетләре.

Яшим, эшлим дигән кешегә бүген авылда тормыш итәргә була. Башны гына эшләтергә кирәк. Кемнәрдер терлек асрап, икенчеләр иген үстереп көн күрергә тырыша. Ә менә Кайбыч районы Чүти авылында яшәүче Дамир Шәрәфетдинов авылдашлары, якын-тирә авыл халкы өчен агач яру цехы ачып җибәргән.

Бу эшкә керешкәнче, Дамир җизнәсе белән киңәшләшә дә, бергәләп тиреләр җыя башлыйлар. Аннан планнарын үзгәртергә булалар. Район халкы терлекне күп асрый, җитештергән итләрен кая урнаштырырга белмичә тилмереп йөргәннәрен күреп, Түбән Кама шәһәренә ит илтеп карарга уйлыйлар. Теләсә-нинди итне алмый егетләр, ислам кануннары буенча чалынган терлекне генә сатып алып, хәләл кибетләргә ташырга керешәләр. Менә шулай итеп икенче көсепне башлый алар. Аннан инде авылда хәләл ризыклар сатыла торган кибет тә ачып җибәрәләр.

Ит тиз бозыла торган ризык. Түбән Кама Кайбычтан шактый ераста урнашкан. Егетләр тагын уйлана башлыйлар. Киңәшле эш таркалмый, диләр бит. Уйлашканнан соң, уртак фикергә килеп, агач яру цехы булдырырга карар кылалар. Авылда бушап калган балалар бакчасы бинасын сатып алып, шунда эшләрен башлап җибәрәләр. Төзелеш материалларын эшкәртә башлый алар.

Чүтигә килеп кергәч тә, авыл уртасындагы агач яру цехына игътибар иткән идем. Баштарак мин аны күмәк хуҗалыкныкы дип уйладым. Ялгышкан булып чыктым, шәхси кешенеке ул, җитәкчесе бик тырыш егет, диделәр миңа. Чыннан да шулай булып чыкты. Дамир күп сөйләргә яратмый. Башкарган хезмәтләре турында бик аз сөйләде. Проблемалары турында да әйтергә теләмәде.

Агачларны Чуашиядән алып кайталар икән. Шуны такта итеп ярдырып, халыкка саталар. Калган төзелеш материалларын исә заказ буенча эшлиләр. Нигә агачны читтән алып кайтасыз, дигән соравыма Дамирның җавабы кыска да, аңлаешлы да булды: «Бездә агачны сатып алу кыенрак», — диде ул.

Алар агач материаллары белән генә эш итми. Авыл халкына нинди төзелеш материалы кирәк, барысын да заказ буенча кайтарталар. Калаен да, цементын да, башкасын да...

Ике ел элек пластик тәрәзәләр ясарга керешкәннәр. Бер ара тәрәзәләргә заказлар бик күп булган, ә кыш көннәрендә эшләре бераз кимеп киткән. Дамир әйтүенчә, төзелеш сезонлы эш. Шуңа күрә дә эшләр кайбер чакта бетеп тә торгалый. Яз, җәй айларында исә эшнең кызган мәле. Бу чорда заказлар да шактый җыела. Төшенкелеккә бирелә, проблемалар алдында югалып кала торган кеше түгел ул, алга максат куеп, тормыш алып барырга яңа планнар кора.

10нан артык авыл кешесен эшле иткән агач ярдыру цехындагы чисталык, пөхтәлек берәүнең ишегалдында да юк. Тигезләп өеп куйган сайгаклар, такталар. Чүпләр дә теләсә ничек аунап ятмый. Кешенең тырышлыгы аның эшеннән, территориясеннән үк күренә шул.

Ләйлә ГАЛИМУЛЛИНА.

ГАИЛӘ СӘГАТЕ

Нәрсә булды сиңа, әни?

Әнине үзем танышу хезмәтенә хат язып карарга күндердем. Иң кадерле кешемнең шәхси тормышы җайлануын бик тели идем мин. Аңа әле кырык яшь тә тулмаган, аннан ул бик сөйкемле, тормыш дәрте ташып тора. Әти дигән кешем әнигә өйләнми кала. Яратып йөргән кызының бала көткәнен белгәч юкка чыга ул. Туарга өлгермәгән сабыеның әтисез калганын белгәннән башлап, әни бөтен көчен мине үстерүгә багышлый. Аның җылы кочагы минем өчен әти дә, әни дә булды. Шуңа да моңарчы үз рәхәте өчен яшәргә мөмкинлек булмады аңа.

Әнә шулай әнинең тормышын җайларга теләп, аның ризалыгы белән мин таныштыру хезмәтенә хат язып җибәрдем. Редакциядә хатны бастырып та чыгардылар. Озакламый җаваплар да килә башлады. Аралаша торгач, әни бер ир кеше белән танышты. Мин аның хакында бернәрсә дә белә алмадым. Тик әнинең нурлы йөзләренә карап сөенә башладым. Күзләре ялтырый, һәрвакыт күтәренке кәеф белән йөри. Бәхетле булуы әллә кайлардан үк күренә иде.

...Озакламый безнең фатирга әнинең сөйгәне килеп йөри башлады. Беренче тапкыр күргәндә бөтенләй аптырап калдым. Каршымда яшь бер ир-атны күреп хәтта телсез кала яздым. Ул әнидән 15 яшькә кечерәк булып чыкты. Шундый акыллы, сөйкемле әниемнең шушындый кыяфәтсез яшь кеше белән аралашып китәр дип башыма да китерә алмадым. Сүгенү сүзләрен кыстырмыйча, ул хәтта сөйләшә дә белми иде. Әмма икесе дә күзгә карап, бер-берләрен яратуларын әйткәч, шатланырга да, көенергә дә белмәдем. Мәхәббәтнең көчен бәяләп бетереп булмый ул, ошатышырлар да, бер-берсеннән туярлар да дип өмет иттем. Тик барыбызны да шаккатырып, алар бергә яшәргә теләүләрен белдерделәр.

Уртак тормышта барысы да беленә бит. Гаиләдә үпкәләшү, талашулар башланып китте. Аларның мөнәсәбәтләре мине борчуга салды. Әнине юкка рәнҗетүен күреп, мин аны инде күрә алмый башладым. Мәхәббәт шундый буламы инде ул? Яраткан хатын-кызга гел сүгенеп торырга ярыймы икән? Әни исә яраткан кешеләр арасында ни булмас дип куя иде. Әнинең сөйгәне исә көннән-көн тискәре якка үзгәрә башлады. Көн саен эшкә йөрсә дә, без аның алып кайткан акчаларын күрмәдек. Шулай да һәрвакыт тамагы тук, өсте юылган-чистартылган иде. Өстәвенә әни аны чынлап торып яратып яши. Әнә шундый рәхәтлеккә чыккач, ул бөтенләй эшен дә ташлады. Аны бит инде болай да яраталар. Бу хакта ул әйтергә дә оялмады миңа. Ачуланырга теләвемне белгәч, хәтта яңагыма сугып җибәрде. Сабырлыгым бетте, түзмәдем, соңгы сүземне әйтеп өйдән чыгып киттем.

Бер әбидә фатирда тора башладым. Хуҗабикәм белән әйбәт яшәдек. Шул кыяфәтсезне күргәнче, әбине каравым хәерлерәк булыр дип уйладым. Язын бик нык чирләп киттем. Әби аптырагач, әнигә шалтыратты. Әни килеп җитте, дарулар алып кергән, җиләк-җимешен дә алган, тик янымда гына озак утыра алмады. «Кызым, мин табиб түгел. Хәлең авырлашса, ашыгыч ярдәм чакырырсыз. Беләсең бит инде Наилне, үзе яшь, үзе гайрәтле. Бер генә итәкне дә читкә җибәрмәс... Китәм, ачуланма!» — диде ул. Мин аптырап әнигә карап калдым:

— Нәрсә булды сиңа, әни?!

Ул борылып карады да чыгып китте. Вакыт үтә торды. Әни белән бер-беребездән шундый ерагайдык. Бервакыт әни килде. Елый-елый үзенең борчуларын сөйләде. Наил автоматта уйнап зур акча оттырган икән, хәзер аңа бик яныйлар, ди. Шуңа дип әни таныш-белешләреннән акча җыеп йөри башлаган. Минем ял итәргә дип сакка куелган акчам бар иде, тик мин аны шул ир заты өчен бирә алмадым. Югыйсә, әллә ничә кат әнидән аерылышуларын сорадым, ул исә һаман аны гафу итеп килде. Үзенең тормышы өчен үзе генә җавап бирәчәген әйтте. Аннан бервакыт минем хат язарга этәрүемне гаепләп тә куйды. Мин бит бары тик әнинең бәхетле генә булуын теләгән идем. Бу сүзләр мине бераз рәнҗетте дә. Хәзер исә әнигә ничек ярдәм итәргә дә белмим.

Рания ФАЗЛЫЕВА.

9299 Хатыны үлгән татар ир-аты, 58-175, 55-60 яшьлек торагы булган хатын-кыз белән танышырга тели.

9306 Зифа буйлы татар кызы, 34-162, гаилә корыр өчен 40 яшькә кадәр булган ир-аттан хәбәр көтеп кала.

9313 Аралашучан, бик тә сөйкемле татар хатын-кызы, 47-163, 47-55 яшьләрдәге ир-ат белән танышырга тели.

9315 72-165, татар ир-аты үз йорты белән яши. Бергәләп тормыш корыр өчен 65-75 яшьлек хатын-кыз белән танышасы килә.

4371 39-165 татар хатын-кызы, балалары юк, тыныч, сөйкемле, ышанычлы, начар гадәтләре булмаган, тормыш юлдашы булырдай ир-ат белән күрешергә тели.

4372 Сөйкемле татар кызы, 30-167, гаилә корыр өчен 38 яшькә кадәрле булган татар ир-егете белән очрашырга тели.

4374 Татар, 44-174, мөстәкыйль, җитди, ышанычлы, 45 яшькә кадәрле хатын-кыз белән танышырга тели.

4378 Татар ир-аты, 53-160, шәһәр читендә үз йорты белән яши. Начар гадәтләре булмаган, намуслы, җаваплы, 50 яшькә кадәрле татар хатыныннан җавап көтеп кала.

ҖАВАП хатларыгызны түбәндәге адреска юллый аласыз.
420126, Казан шәһәре, Амирхан проспекты, 2, «Служба знакомств».

№_____ өчен яисә тел./факс аша 521-44-31;
svaha-kzn@rambler.ru
znakomstvo-kazan.ru

ХУҖАБИКӘГӘ

Сыр ясыйбыз

Моның өчен 2 литр сөт, 2 килограмм эремчек, 200 грамм атланмай, 2 йомырка, 2 чәй кашыгы тоз, 2 чәй кашыгы чәй содасы кирәк.

Сөтне кайнатып чыгарырга. Шуңа алдан әзерләп куелган эремчекне салырга, болгата-болгата кайнап чыгар дәрәҗәгә китерергә, ләкин кайнатып чыгармаска. Марля аша сыгарга да, әче суы сарыксын өчен 10-15 минутка элеп куярга.

Эмаль кәстрүлдә 200 грамм атланмайны эретергә. Шуңа 2 йомырка,чәй содасы,тоз өстәргә дә, яхшылап болгатырга. Марлядагы эремчекне кәстрүлгә салып, сүрән утта бер төрле массага әйләнгәнче, төбенә утырмасын өчен болгата-болгата пешерергә. Сыр «колобок» рәвешенә кергәннән соң әзер була. Әлеге массаны атланмай белән майлаган савытка бушатып, суытырга куярга.

СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНДА

Иселе дә йолдыз аның

2010нчы ел — артистлар юбилейларына бай ел буларак тарихка кереп калыр, мөгаен. Ел башланганнан бирле, концерт залларына артистларны котларга халык агыла. Чираттагы күркәм тамаша М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узды. Анда яраткан җырчыбыз Венера ГАНИЕВАНЫҢ юбилей кичәсе үтте.

Аңа кадәр, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә Россия һәм Татарстанның халык артисты Венера Ганиевага «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» орденын тапшырды. Бу хактагы указга Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев кул куйган булган.

«Бу мактаулы бүләк Татарстанда яшәүче берничә кешедә генә бар. Хәзер аларга Венера Ганиева да өстәлде, — диде кичәдә мәдәният министры Зилә Вәлиева юбилярны котларга чыккач. — Ул классик партияләрне дә, халык җырларын да бер үк югарылыкта башкаручы талантлы җырчыларның берсе».

«Мондый бүләкне алу минем өчен зур бәхет һәм олы җаваплылык та, — диде Венера Ганиева. — Әлеге орден миңа алга таба тагын да яхшырак эшләргә этәргеч булыр».

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, студентлары өчен Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының вокал кафедрасы мөдире булган Венера Ганиеваның иҗатын кемнәр генә яратмый икән. Венера ханым сәхнәгә чыккач, гүя, кояш чыга, зал нурга күмелә. Халыкның сөекле җырчысы шәкертләрен дә сәхнәне яратырга, килгән тамашачыларга рухи байлык таратырга өйрәтә. Яшьләрнең остазы инде профессор дәрәҗәсенә ирешкән.

Сәләт дигән могҗиза һәр кешедә бар. Әмма аны балачактан күрә белергә, кече яшьтән шөгыльләнергә кирәк. Бу яктан Венера бәхетле. Чөнки сизгер күңелле әти-әнисе аңа вакытында юнәлеш бирә алган. Венера Ганиева Казанның Г.Ибраһимов исемендәге 89 нчы татар мәктәбендә белем ала. Аннары Казан музыка училищесы һәм Казан дәүләт консерваториясендә укый. Укыган вакытта әнисе вафат була. Җырчы тормышының бөтен мәгънәсен югалта. Әмма әнисенең үләр алдыннан: «Җырчы бул!» дигән васыяте аңа кайгыны җиңәргә ярдәм итә.

Мәктәптә укыганда ук Венера Ганиева «Саз» ансамбленең солисты була. 1983 елдан — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты. Бүген ул остазы Нәҗип Җиһановның сүзләрен, аның теләктәшлек күрсәтүен рәхмәт хисләре белән искә ала. Татар халкына билгеле шәхес, булачак җырчыга зур өметләр баглый һәм ялгышмый. Венера бишенче курста укыганда ук төп рольләрне башкарырга керешә. «Кармен»да Микаэла, «Риголетто»да Джильда, «Травиата»да Виолетта — болар классик әсәрләрдән берничәсе генә. Милли әсәрләрдән исә «Алтынчәч», «Наемщик», «Ерактагы көккүк авазы», «Башмагым» музыкаль әсәрләрендәге образларны ул йөрәге аша үткәреп, тамашачыга җиткерә.

Шунысы кызык, кечкенә чакта Венера Ганиева опера җырлаганнарын ишетсә, радио яисә телевизорның тавышын тиз генә кысып куя торган булган. Җырчы үзе исә опера сәнгатенә мәхәббәтне кешедә тиз генә уятып булмый дигән фикердә.

Венера Ганиеваны тамашачы ярата. Опера сәнгатеме, эстрадамы — һәр җирдә аның үз тамашачысы бар. «Туй күлмәге», «Яратыгыз», «Зинһар өчен, кермә төшләремә», «Зәңгәр томан» кебек җырлары бик күпләрне әсир итте. Әмма ул тамашачы мәхәббәтен башкару осталыгы белән генә түгел, ә гадилеге белән яулагандыр. Аның гадилеге, кеше хәленә керә белүе Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында студентлар белән уртак тел табарга да ярдәм итә. Ул алар белән профессор каланчасыннан түгел, әниләре кебек якын итеп сөйләшә. Менә шуңа да аны студентлары икенче әниләре кебек якын итә дә. Студентларын очрата икән, хәлләрен белешә, тулай торактагы проблемалары белән дә кызыксына. Ә менә укуга килгәндә, берәүгә дә ташлама юк. Иҗатта таләпчән, җитди кеше ул. Студентларының берәр образга теше үтми икән, ул шунда ук сәхнәгә менә, бар нечкәлекләреңә төшенеп өйрәнсеннәр өчен уйнап, җырлап та күрсәтә.

Опера белән янәшә эстрада сәнгатендә дә танылу — ул бик сирәкләргә генә эләгә торган бәхет. Белгечләр аңа эстрада җырларына алынма, профессиональ үсешеңә комачаулар, дип кисәтә. Ә ул, сәләт бирелгән икән, чикләнеп калмаска, аны тулы куәтенә файдаланырга карар итә. Һәм ялгышмый да, җыр сәнгате аркасында тамашачысы тагын да арта гына.

Эстрадага яңалык та алып килә ул. Татарстанда беренчеләрдән булып фонограмма куллана башлый. Гастрольләргә җырның музыкасын аудиокассеталарда алып бару гадәтен кертә. Көйнең беренче аккордлары яңгырый гына башлый, залдан: «Син нәрсә магнитофон кычкыртасың, без тере тавыш тыңларга килдек», — дип ризасызлык белдерә башлыйлар. Аңа фонограммага кушылып үз тавышы белән җырлавын исбатлар өчен микрофонны читкә куеп торып, җырларга туры килә.

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында утыздан артык опера партияләре башкару, «Татарстан» радиосы фонотекасында сакланган ике йөзләп җыр — бусы аның бәхетле иҗатының саннарында чагылышы. Әмма аңа ирешер өчен үзеңне күпме чикләргә кирәклеген, көеф булмаганда да елмаерга тырышуның нәрсә икәнен ул үзе генә белә. Иҗатташ дуслары аның хакында, хисчән, хәтта беркадәр дуамал, әгәр иҗатын чагылдырыр өчен яңа алым уйлап чыгарылса, ул, һичшиксез, аны башкарып чыгачак, диләр. Санкт-Петербургтагы Мария театрының баш режиссеры Алексей Степанюк исә: «Ул алдан ук оста иде, хәзер дә шулай калды», — дигән бәя бирә.

Яшьлегенең чәчәк аткан мәлендә концертлар белән Татарстанның һәр районында гына түгел, чит төбәкләрдә дә концертлар куеп йөргән Венера Ганиева хәзер дә кимен куймый. Һәм Казанга сагынып, ашкынып кайта. «Бу минем яраткан, туган шәһәрем. Бөтен дөньяны диярлек әйләнеп чыксам да, минем өчен Казаннан да матуррак һәм якынрак шәһәр юк», — ди ул.

— Кеше нинди генә яшькә җитсә дә, туган көнен уфтанып түгел, ә күтәренке күңел белән, рәхәтләнеп каршы алсын иде. Яшьлек үтә инде ул, әмма хатирәләр, җырлар белән аңа кире кайтып була бит. Иң мөһиме, күңел халәтең белән яшьлектә калырга кирәк. Ә ике бишлегә килеп җитү — һич тә начар түгел. Бу түгәрәк «отличница» дигән сүз бит. Иҗатымда да, гаиләмдә дә мин бәхетле. Юбилей концерты тикмәгә генә «Мәхәббәттә аңлашу» дип аталмады. Мин остазларыма, әти-әниемә, дусларыма, коллегаларыма һәм тамашачыма мәхәббәтемне белдердем, — ди Венера ханым.

Диләрә ФӘТХУЛЛИНА.

МӘЗӘКЛӘР

Кафега бер кеше кереп, өстәл янына утыра. Аның янына официант килә.

— Тыңлыйм сезне...

— Тыңла, миңа бер бокал коньяк, бер бокал аракы, бер бокал шәраб, бер бокал ликер, бер бокал шампанский, бер кружка сыра һәм бер стакан чәй китер! Бетте, җитәр. Әмма чәйне бик каты итеп ясамагыз, минем йөрәгем авырта...

* * *

Бер ир икенчесеннән сорый икән:

— Син биш мең доллар акчаң булуын теләр идеңме, әллә биш кызмы?

— Биш кыз.

— Ни өчен?

— Чөнки минем болай да җиде кызым бар...

* * *

Миңа 20 яшь булганда, 30 яшьлек хатын-кызлар да ярыйсы гына иде. Хәзер миңа 40 яшь, 30 яшьләр инде карт булып күренә.

* * *

Ир автовакзалның ашханәсенә керә. Бер ир янына утыра. Таныш булмаган ир аш ашап утыра.

Беренче ир сүз башлый:

— Сез Череповец шәһәреннән түгелме?

Икенче ир:

— Угу.

— Камилне беләсеңме?

— Угу.

— Аның хәле ничек?

— Үлде.

— Сәлаховның апаларының хәле ничек?

— Үлделәр.

— Нәрсә, сездә берәр төрле фаҗига булмагандыр бит?

— Юк.

— Эпидемия?

— Юк.

— Алай булгач нәрсәдән үлделәр соң?

— Ашаган вакытта мин бу дөньяда үземне ялгыз хис итәм. Башкалар минем өчен үлгән кебек.

* * *

Юлаучы елга янына килә. Яр кырыенда бер егет утыра. Ярты сәгать чамасы аны күзәтә. Егет кымылдамый да, кармагын тоткан да, суга карап тик кенә утыра. Килгән кеше түзми, сүз ката:

— Балыкчы, балыкны күп тота алдыңмы?

— Менә берне тотсам, тагын берне каптырсам ике була.

* * *

— Мин тартуны, эчүне ташладым бит әле. Ашауны да киметтем.

— Ничек, үзеңдә үзгәрешләр сизәсеңме соң?

— Билгеле, хәзер минем гел тартасым, эчәсем, ашыйсым гына килеп тора.



1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11

Р.АБЗАЛОВ төзеде.

cyan magenta yelow black